**Литература**

1. Абылкасымов Б. Телконыр (Казактын коне наным-сенимдерине катысты гурыптык фольклоры). – Алматы: Атамура-Казакстан, 1993. – 163 с.
2. Гордлевский В.А. Избранные сочинения. III т. История и культура. –М.:Издательство восточной литературы, 1962. – 591 с.
3. Казактын мифтік ангимелери. Курастырып, гылыми тусиниктемелерди жазгандар: Ш.Ибраев, П.Ауесбаева. – Алматы: Гылым, 2002. – 320 с.
4. Турки халыктарынын хикаялары. Жинакты курастырып, баспага дайындагандар: Ш.Ибраев, А.Ахметбекова, П.Ауесбаева. – Алматы: ИП «Сагаутдинова». – 2014. – 415 с.

**Вафина Альмира Мухаматназиповна,**

*учитель татарского языка и литературы МБОУ "СОШ № 62",*
*г. Казань, Республика Татарстан, Россия,*
*e-mail: almira.vafina@bk.ru*

УДК 82.512.145

# М. МИРЗА ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ АНА ОБРАЗЫ

# ОБРАЗ МАТЕРИ В ПОЭЗИИ М.МИРЗЫ

# THE IMAGE OF THE MOTHER IN POETRY M.MIRZY

**Аннотация.** В статье рассматривается образ матери в стихотворениях М.Мирзы. Анализируя образ матери в стихотворениях вышеупомянутого поэта, автор раскрывает различные социально-нравственные проблемы, и тем самым определяет идея-тематику творчества писателя.

**Abstrakt.** The article deals with the image of the mother in the poem M.Mirzy. Analyzing the image of the mother in the poems of the above mentioned poet, the author reveals a variety of social and moral issues, and thus defines the idea and the theme of the writer.

**Ключевые слова.** поэзия, образ, мать.

**Keywords**. Poetry , image, mother.

Гомерләрнең көзе түгел,
Җәйге чагы:
Дөнья йөге арбасына
Бәйле чагы.
Үргә менеп, каерылып бер карагач:
–Сөбханалла, иншалла! – дип
Әйтер чагы...
М. Мирза

Әниләр турында булган бер генә язма да беркемне дә битараф калдырмас. "Ана" исеме элек ни дәрәҗәдә бөек булса, бүгенге көндә дә шул дәрәҗәдә бөек.

Татар Әдәбиятында Ана образын яктырткан әсәрләр шактый күп. Борынгы әдипләребез хатын-кызларның хокуксызлыгына борчылсалар, соңрак язылган әсәрләрдә исә аларның батырлыкларына дан җырлана, чорның рухи-әхлакый эчтәлеге ачыла. Мәсәлән, Т.Миңнуллинның "Әниләр һәм бәбиләр", Ш.Хөсәеновның "Әни килде", А.Гыйләҗевның "Җомга көн кич белән" пьесаларында Ана образына бәйле рәвештә буыннар бәйләнеше, рухи-әхлакый кыйммәтләргә мөнәсәбәт кебек проблемалар күтәрелә.

Мөхәммәт Мирза иҗаты турында сөйләгәндә дә Ана образына тукталмый мөмкин түгел. Язучы шигырьләрендә без сагышлы аһәң – Ана гаме, Ана моңын күрәбез. Бу хистә шагыйрь бик тирәнгә керә алган. Ул үз әсәрләрендә бала белән Ана арасындагы илаһи бәйләнешне гына ачып калмый, бәлки, шушы хис ярдәмендә ил язмышы, милләт язмышы кебек олпат уйларга да күпер сала:

Карашыңны тоям һәр тарафта:
агып барган апа-ак болыттан да,
ак күбеккә баткан шомырттан да,
бармак имеп яткан оныктан да... [3, б. 88.]
("Әнкәй")

Шул рәвешле, шагыйрь Әнкәй образы аша туган нигез, туган авыл, туган ил төшенчәләренә чыга һәм аларның да саллы, тирән мәгънәле образын тудырырга омтыла.

Яз төгәлләнеп, җәйгә кереп барган мәлдә, шагыйрь М. Мирзаның “Казан” милли мәдәният үзәгендә түгәрәк датасына багышланган гаҗәеп бай эчтәлекле кичәсе булган иде. Бәйрәмдә Галиәсгар Камал артистлары бик матур итеп шагыйрьнең шигырьләрен укыйлар. Мөхәммәт Мирза һәм аның хәләл җефете Рушания ханым “Әнкәй” поэмасын укыйлар. Залда тамашачы поэманы тыңлап тынсыз кала [4, б. 6].

Кичер, Әнкәй,
Ничә кабат җыенып та,
Бер җыр да яза алмадым синең хакта.
Сүзләремнән баскыч тезеп,
Үрелсәм биеклегеңә,
Кимчелек китермәм микән,
Әнкәм, бөеклегеңә? [1, 96 б.]

Иман... Иманлы кеше булу... Халкыбыз аңына бик борынгыдан сеңгән төшенчәләр бу. Иманлы булу – ул динле булу, дингә табынып яшәү дигән сүз генә түгел, ул әхлакый кагыйдәләр буенча тормыш итүне аңлата. М.Мирзаның әлеге поэмасында да халкыбызның матур сыйфатларын үзендә туплаган иманлы, югары әхлак сыйфатларын үзенә туплагагн Ана образы калка. Ул авылыннан, туган җиреннән аерылмаган, хезмәт белән көн күргән, мал-туар, кош-корт асраган, ире белән балаларын тәрбияләгән, аларга югары белем бирә алган. Гади генә укыла торган, әмма әнисе Мөсәвәрә апаның тормыш фасылларыннан тезелгән юлларга чумасың. 11 бала табып үстергән Ананың күргән-кичергәннәре бер поэмага гына сыярлык түгел. Шуңа күрә “Куян күчтәнәче” дип аталган икенче әсәрдә Ана образын очрату гаҗәпләндерми.

Күз алдымда җуелмаслык сурәт:
бер менеп, бер төшеп буразнасын,
басу буйлап Әнкәй кайтып килә –
иңдә – чалгы, кулда – куларбасы.
Иңсәсенә салган унлы чалгы,
тиеп-тиеп китә болытларга.
Итәгенә ябышып, мин атлыйм:
Калмаска тиешмен бер тотам да...[2, б. 260].

Унбер баланың һәрберсе олы юлга Әнкәй итәгенә тотынып чыгып киткән. Ә бу Әнкәйне һәм аңа ияргән балаларны Әткәй каршылый:

Протезларын салып куйган Әткәй...
Тезләрендә атлап килде дә
алмаш-тилмәш безне күккә чөйде:
Бөркетләрем минем! – диде дә...[2, б. 262].

Әнә шулай балаңны бөркеткә тиңләп, матур омтылышлар белән тәрбияләсәң генә алар зур тормыш күгендә дә бөркет кебек кагына ала шул.

Ана образы шагыйрьнең гомер һәм иҗат юлын бүген дә яктыртып тора. Сынмас рухлы, көчле шәхес итеп сурәтләнгән, аякларын югалткан ата образы да җанны тетрәтә (Мөхәммәт Мирзаның әтисе 18 яше тулган көнне, 1943нче елда, Днепр ярында аяксыз кала һәм “Бары да бетте!” – дигән уй баш миен яшен кебек көйдереп ала. Тик ялгыша Мирза абый! Сугыштан исән-имин кайтып, 11 бала үстерергә насыйп була аңа. Шагыйрь Илфак Ибраһимов әтисенең исемен псевдоним итеп ала: Мөхәммәт Мирза) [4, б. 6].

Әмма, балачакның һәр мизгеле
Кабатланмас бәхет булган ул.
Җил капкалы Әткәм-Әнкәм нигезе
сыендырган, туендырган ул –
гел игелек белән тулган ул! [2, б. 262]

Шулай итеп, укучы алдына үзенә бөтен уңай сыйфатларны туплаган татар хатын-кызы образы куела. Билгеле булганча, элек-электән татар хатыннары ирләренә таяныч булганнар. Эшләре белән дә, киңәшләре белән дә ярдәм иткәннәр.

М.Мирзаның “Сабыйлык хатирәсе” язмасында да бала чагына, әнисенә карата булган җылы, якты истәлекләрен бирә: “Балачакның онытылмас истәлекләре бихисап күп, әмма иң җанга якыннары әнкәебез пешергән ризыклардыр, мөгаен. Өйнең астын-өскә китереп туздырып бетерсәк тә, шуклыклар белән үртәшүләр, бәргәләшеп алулар булса да, табын артында шылт иткән тавыш та чыкмас иде... Күрәсең, өстәл артына бик ачыгып утырганбыздыр... Әмма беркайчан да ач торганыбызны, ашамый йоклаганыбызны хәтерләмим... Әнкәй генә шулай тәмле пешергән тары тәбикмәге, күкәй күмәче, көлчә, бәрәңге шаңгәсе, кыстыбый, каты камыр, каз ите кушып пешерелгән дөге, тары боткасы, угыз актының тәме әлегәчә тел очында тора. Әмма ишле гаиләдә, көнаралаш бер мич эпи пешергән гаиләдә артыгын төрләнергә мөмкинлек тә булмагандыр... Барыбер дә кайнар күмәч, тәгәрәткән бәрәңге һәм катыктан өзелмәгән, сугыштан соң дөньяга килгән бәхетле балалар идек без” [5 ].

Шагыйрь әнисен шигырьләрендә батыр йөрәкле, яхшы күңелле, көчле, намуслы, акыллы хатын итеп

сурәтли. Гомумән, ана образы аша һәр чорның асылы, рухи-әхлакый кыйммәтләр системасы ачыла. Ана образы тудыручы, саклаучы һәм яклаучы буларак гәүдәләнеш таба. Язучының шигырь-поэмаларында бу образ бөтен тулылыгы, эчке матурлыгы, мөлаемлыгы белән ачыла. Ул әсәрләрдә М.Мирзаның анасына булган иң изге хисләре, йөрәктән кайнап чыккан кичерешләре, уй-хыяллары чагылган.

**Әдәбият**


1. Мөхәммәт М. Кәккүк тавышын санадым...: шигырьләр, поэмалар / кереш сүз авторы Р. Мингалим. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 107 б.
2. Мөхәммәт М. Киек каз юлында: шигырьләр, газәлләр, поэмалар / кереш сүз авторы М. Вәли-Барҗылы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 300 б.
3. Мөхәммәт М. Турайгыр: шигырьләр, поэмалар / кереш сүз авторы Г.Гыйльманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 168 б.
4. Юнысова А. Уйчан шигырьләр // Ватаным Татарстан. – 2003. – 14 ноябрь.
5. http://matbugat.ru/



**Габидуллина Фарида Имамутдиновна,**

*к. филол. н., доцент кафедры татарской филологии,*
*Елабужский институт К(П)ФУ,*
*г.Елабуга, Республика Татарстан, Россия*
*e-mail: farida-vip@mail.ru*



УДК 821.512.145.


# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА КАТНАШ НИКАХ ТЕМАСЫ

# THE TOPIC OF MIXED MARRIAGES IN TATAR LITERATURE


**Аннотация.** В статье на примере творчества современных писателей Т.Галиуллина и Р.Зайдуллы рассматривается тема смешанных браков.



**Ключевые слова:** татарская литература, семья, герой, тема, нация.



**Abstract.** This article deals with the topic of mixed marriages on the basis of literary works by modern Tatar writers - T. Galiullin and R.Zaidulla.



**Keywords:** Tatar literature, family, character, theme, nation.


Мәгълүм булганча, катнаш гаиләдә, кагыйдә буларак, аңлашу-аралашуда бердәнбер тел булып рус теле кала. Әйтик, рус-татар (татар - әни), рус–чуаш (чуаш - әни) һ.б. кушылган гаиләдә рус теле хакимлеге күзәтелә. Нәтиҗәдә, нигездә балалар бары тик шушы тел мохитендә тәрбияләнәләр. Аларның татар, чуваш, мари... халык мәдәнияте белән элемтәсе бөтенләй булмый, йә инде ташка үлчим дәрәҗәсеннән узмый. Бу – бер милләт вәкиле буларак үзеңне юкка чыгару дигән сүз. Катнаш гаилә төзүгә каршы килүчеләрне нәкъ менә күп телләр урынына бер тел, күп милләтләр урынына бер милләт калу проблемасы борчый. Алар яхшы беләләр: җирдә бары бер төсле чәчәк, бер төр үсемлек калса, табигать, җир йөзе никадәрле ярлы, хәерче булыр иде. Катнаш гаиләләрнең күпчелеге бүгенге көндә әнә шул бертөрлелекне тудыра.

Әлбәттә, бу мәсьәлә күп кенә язучыларыбызны да борчый һәм аларның әсәрләре нигезенә ята. Х йөз башында әлеге теманы милли әдәбиятыбызның классигы Г.Исхакый (1878-1954) да яктырта. Милли моңны, телне бала әнисеннән ишетә. Сабый милли рухта үссен өчен, аны милли мохит, милли йолалар, милли традицияләр нигезендә тәрбияләргә кирәк. Шушы хакыйкатьне аңлап, Г.Исхакый «Ул әле өйләнмәгән иде” (1916) повестен иҗат итә. Повестьның төп герое – Шәмси укымышлы, рус мәдәнияте йогынтынтысында тәрбияләнгән егет, бернинди икеләнү кичермичә, рус хатыны белән аралаша башлый. Соңыннан, Анна Васильевна балага узу сәбәпле, яшьләр өйләнешәләр. Әмма ничек кенә яхшы яшәргә тырышсалар да, рухи яктан Шәмси белән Анна арасында үтеп чыга алмаслык упкын хасил була. Гасырлар буе буыннан-буынга күчкән милли хис, дини йогынты аларның һәр икесенең эчке халәтен бер генә минутка да күздән ычкындырмый: “Ул тагы тора бирде. Тагы шул тормышка керә бирде. Тагы, хөррияте диния була бит дип, үзен юата килде” [3, б.416]. Г.Исхакый дини, милли каршылыкларга нигезләнеп корылган гаиләнең фаҗигага илтүен әнә шулай сурәтли.

Хәзерге татар әдәбиятына әлеге тема Ф.Латыйфи, Р.Зәйдулла, Т.Галиуллин, А.Хәлим, Т.Миңнуллин һ.б. әдипләребез иҗатында дәвам иттерелә. Яраткан әдибебез Т.Галиуллинның «Кияү» (1994) повестенда да әлеге мәсьәләнең үзәктә булуын күрәбез. Әсәр өйләнү-тормыш итә башлау вакыйгаларын кабатлау кебек